# Күршеңне хөрмәт ит

Күрше хакы турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам үзенең бер хәдисендә болай дигән: *«Әгәр кеше Аллаһы Тәгаләгә ышанып, иман китерсә, үлгәннән соң терелүгә ышанса, тәкъдирнең начарына да, яхшысына да ышанса, күршесен хөрмәт итсен, рәнҗетмәсен, тынычлыкта тотсын»*.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәламнең күршесе һәркөнне аның өе янына, ул йөри торган юлга чүпләрен чыгарып түгә торган булган. Көннәрдән бер көнне Мөхәммәд галәйһис-сәламнең юлына чүп түгелмәгән. «Әллә күршем чирләдеме икән?» – дип, ул аның хәлен белергә керә. Гел начарлык эшләсәм дә, ул минем хәлемне белергә кергән, дип күршесе бик нык гаҗәпләнә. Шушы хәлдән соң гел начарлык эшли торган күршесенең күңеле үзгәргән, ул иманга килә, мөэмин-мөселман булып, яхшы күршегә әйләнә.

Күршеңнең кайгысына сөенмә. Чөнки Аллаһы Тәгалә аңа рәхим-шәфкать кылырга, ә сиңа бәла-каза җибәрергә мөмкин. Үз туганнарыңнан соң синең якын кешеләрең булган күршеләр белән яхшы мөгамәлә кылып, шатлык һәм кайгыларын уртаклашып, кирәк булганда аларга булышып, хәер-догаларын алып тору - бик саваплы гамәл. Күршеләрне хөрмәт итеп яшәргә кирәк, аларның хәтерләрен калдырырга һич тә ярамый. Күршеләрегезнең нәрсә эшләгәннәрен, нәрсә сөйләгәннәрен качып тыңлап тормагыз, гайбәтләрен кешегә сөйләп йөрмәгез, яла якмагыз. Киресенчә, һәр эштә аларга булышырга тырышыгыз. Аллаһы Тәгалә: *«Күршесен рәнҗеткән кеше җәннәткә кермәс»*, – дип боерган. Коръәндәге «Ниса» сүрәсенең 36 нчы аятендә: *«һәрвакыт күршеләрегезгә игелек кылыгыз»*, - диелә.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Сабырлык белән үткәр

Арабызда: «Башка кешеләр рәхәт яшиләр, бер кайгылары да юк, кайгы гел миңа гына килә», – дип йөри торган кешеләрне әледән-әле очратырга мөмкин. Болай уйлау хата һәм Аллаһы Тәгаләгә тел-теш тидерүгә кайтып кала, Аллам сакласын. Әгәр шул «рәхәт, бернинди кайгысыз яшиләр» дип уйлаган кешенең хәлләре тикшереп каралса, ихтимал, алардагы кайгылар тагы да зуррак булуы ачыкланыр. Дөнья – кайгы йорты, бер сәгать шатлыгы булса, ике сәгать хәсрәте була.

Сабыр итүчеләр һәм Аллаһы Тәгалә тарафыннан килгән казаларга риза булып торучылар хакында Коръән-Кәримдә зур вәгъдәләр бар. Шул вәгъдәләргә ышанып, гамәл-гыйбадәт кылучыларның бәхетле булуларында шөбһә юк. Килгән бәлаләргә сабыр итү һәм казаларга буйсыну – бәла булмый һәм казалар күрелми торган җәннәтләргә алып бара торган бердәнбер юл. Адәм баласының дөньяда яшәгән вакытта кайгы-хәсрәтләр күрмичә гомер сөрүе мөмкин түгел. Мәгыйшәт һәм хәят тигәнәк һәм чәнечкеле агачлар өстендә йөрүдән, мәшәкать дулкыннары белән көрәшеп яшәүдән гыйбарәт. Акыллы кеше шушы мәшәкатьләрдән авырсынмаска һәм киләчәктәге рәхәтләрне өмет итеп алардан җиңелмәскә, күңелен төшермәскә тиеш. Чөнки Коръән-Кәрим һәр авырлык соңында җиңеллек булуын вәгъдә кыла. Мәселман кеше, әлбәттә, шул вәгъдәне хәтерләп, күңелен юатыр һәм үзенә нәсыйхәт дәресләре бирер.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

***БӘЕТ***

# Йөрәгемдә яши олы сөю

**(Яраткан иремә багышлыйм)**

*Йөрәк әрни, бәргәләнә күңел,*
*Сагышларга юк бит дәва да.*
*Ялгыз аккош кайгыларым аңлап,*
*Җан авазга кычкыра һавада.*

*Мин талпынып җирдән күтәреләм,*
*Сынаса да язмыш сындырып.*
*Ике балам яшәр бу дөньяда,*
*Йөрәгемне, җаным тындырып.*

*Аерса да мине сөйгәнемнән,*
*Мин язмышка башым имәдем.*
*Сындырса да, как-кат сынаса да,*
*Мин бәхетсез булдым, димәдем.*

*Йөрәгемдә яши олы сөю*
*Давылларга каршы барырлык.*
*Балаларым биргән көч һәм дәрман*
*Хәсрәтләргә каршы торырлык.*

**Лилия ДАУТОВА.**
Нурлат шәһәре.



«Әшһәду әллә иләһә илләллаһу үә әшһәду әннә Мухәммәдур-рәсулуллаһ!» дип иман китерәмен!» – дип, нәсара иманга килә. Шулай Гашура көне хөрмәте сәбәпле, фәкыйрьгә ярдәм итүе белән нәсара иман бәхетенә ирешә...

### ГАШУРА КӨНЕ НАМАЗЫ

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһедан риваять кылына: «Кем дә кем Гашура көнен дүрт рәкәгать намаз укып, рәкәгать саен «әл-Фатыйха» уку белән 50 шәр мәртәбә «әл-Ихлас» сүрәсен укыса, Аллаһы Тәгалә аның үткән һәм киләчәк 50 ел гөнаһларын гафу итәр һәм югары күктәге җәннәттә аның өчен бер сарай булдырыр».

Гашура кичәсен гамәл-гыйбадәттә үткәрү мөстәхәб гамәлләрдәндер. Башка бер хәдистә Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам: *«Кем дә кем Гашура кичәсен гамәл-гыйбадәттә үткәреп чыкса, ул Аллаһы Тәгалә каршында нәкъ мукаррабин фәрештәләр, ягъни Аллаһы Тәгаләгә бик якын булган фәрештәләр шикелле булып күренер»*, – дигән.

### ГАШУРА КӨННЕ УРАЗА ТОТУ

Гашура көнне ураза тоту – сөннәт гамәлдер. Мөхәммәд галәйһис-сәлам Гашура көнендә ураза тотучыга карата: *«Гашура көнен уразада үткәрүче кешегә бу көнне ураза тотучы мөселманнар санынча савап һәм шәһитләр савабын бирер»*, – дигән.

– Кем Гашура көнендә берәр ураза тоткан кешегә авыз ачтырса (авыз ачу мәҗлесенә чакырса), барча Мөхәммәд галәйһис-сәлам өммәтен авыз ачтырган кебек әҗергә ирешер.

– Гашура көнен уразада үткәрүче – нәкъ бер елны тулысынча уразада үткәргән шикелле әҗерле булыр.

– Бу көннең фазылын әзләгез, чөнки ул – Аллаһы Тәгалә каршында сайлап куелган бер мөбарәк көндер. Кем бу көнне уразада үткәрсә, Аллаһы Тәгалә аңа янында булган фәрештәләр, пәйгамбәрләр, рәсүлләр, шәһитләр һәм изгеләр әҗерен бирер.

– Гашура көнне ураза тот, чөнки Гашура көненең уразасы бер еллык гөнаһлардан коткарыр.

### ГАШУРА КӨНЕНДӘ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Гашура көнне укыла торган дога да бар. *«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Сүбхәналлаһи миләә-мизәни үә мүнтә-һәл-гыйльми үә мәблләгәр-рида үә зинәтәл-лә мәлҗә үә лә мәнҗә үә лә мәнҗә миләл-лаһи иллә иләйһ. Сүбхәналлаһи гадәдәш-шәфгый үәл-үитри үә гадәдә кәлимәтит-тәммәти бирахмәтиһи әстә-гыйсү лә хәүлә үә лә куввәтә иллә билләһил-галийил-газыйм. Үә һүә хәсби үә нигъмәл-үәкилу үә нигъмәл-мәүлә үә нигъмән-нәсыйр. Үә саллаллаһу галә сәййидинә Мухәммәдин хайри халкый-һи үә галә әлиһи үә сахбиһи әҗмәгыйн».*

**Җәгъфәр хәзрәт МӨБАРӘК әзерләде.**

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Һәрвакыт догада булыйк

*"Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән һәр-нәрсәне сорагыз, чөнки Аллаһы Тәгалә Үзеннән хаҗәт сорауны сөя, гыйбадәтләрнең изгесе – шатлык көтүдер".*

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләмнең әлеге хәдисеннән аңлашылганча, берәү Аллаһыдан хаҗәт сораса, Аллаһы Тәгалә аңа сораган нәрсәне бирер, әмма кешедән хаҗәт сораучы, Аллаһының ачуына дучар була.

Икенче бер хәдистә болай әйтелгән: *«Догабыз, әлбәттә, кабул булачак дип шикләнмәгән хәлдә Аллаһыга дога кылыгыз. Ләкин шуны яхшы белегез: Аллаһы Тәгалә гафил калебтән чыккан доганы кабул итми»*.

Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: *«Дога – ул гыйбадәттер»*. Коръән берничә өлешкә бүленә, шул өлешләрнең берсе догадан тора. Аллаһы Тәгалә Коръәндә безгә дога кылу үрнәкләрен өйрәтте. Шул исәптән Аллаһы Китабында элекке пәйгамбәрләрнең кылган догалары да еш очрый. Әлеге үрнәкләргә карап дога кыла торган булсак, без гыйбадәт кылган булабыз, һәрбер дога өчен әҗере бар.

Һәм шулай ук Аллаһы догаларыбызны кабул итсә, бу дөньяда да, ахирәттә дә бөек дәрәҗәләргә ирешербез, иншә Аллаһ.

Күбебез яшьтән үк дога кылып үстек. Җомга көннәрне, шатлык килгәндә, хәсрәт-кайгы килгәндә, нинди генә хәлләттә булганда да укый торган доганы барыбыз да беләбез. Ул доганы хәтта намаз укымаган кешеләр дә белә, белмәсәләр өйрәнсеннәр, язып алсыннар. Бу дога - бөтен догаларның да патшасы: *«Раббәнәә әәтинәә фи-д-дуньйәә хәсәнәтәү вә фи-л-әәхыйрати хәсәнәтәү вә кыйнәә газәәбәннәәр»*. Мәгънәсе: *«И, тәрбия кылучы Аллаһ, и, Раббым, шушы дөньяда һәм ахирәттә безгә изгелекләр, яхшылыклар, хуш, яхшы тормыш насыйп итсәң иде»*.

Бервакыт бер гарәп кешесе Мөхәммәд галәйһиссәләмгә әйтә: «Әгәр Аллаһы Тәгалә миңа ара ягыннан якын булса, мин Аңа шыпырт кына ялварырмын, инде Раббым миннән еракта булса, мин аңа кычкырып ялварырмын».

Әлеге вакыйгадан соң яңа аять иңә һәм һәрнәрсәгә ачыклык керә: *«Әгәр бәндәләрем синнән Минем турында сорасалар, Мин, хакыйкатьтә, якын бит, Миңа дога кылып үтенүченең догасына җавап бирермен. Шуңа күрә алар Миңа җавап кайтарсыннар һәм Миңа инансыннар! Шаять, тугры юлга басарлар»* («Бәкара» сүрәсе, 186 нчы аять).

Кеше доганы һәркөн, һәрдаим кылырга тиеш. Дога кылу өчен уңайрак вакытларның булуы да мәгълүм. Мәсәлән, төннең өченче өлешендә яки яңгыр яуган вакытта дога кылу аеруча әһәмиятле.

Шулай ук догаларны һәр изгелектән соң кылырга мөмкин. Мәсәлән, намаз укыгач яки ураза вакытында. Җомга көнне исә, галимнәр фикеренчә, бер сәгать бар - бу сәгатьтә кылган

№ 48 (1175), 24 ноябрь 2012 ел